# Татарстан яшьләре

N 10

(8732)

СИШӘМБЕ

26 гыйнвар, 1993 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *


**Игътибар: идея!**

## Дискотека, ягъни Балтач базары

Яшьләр оешмасы дигәч, келт итеп хәтергә комсомол килеп төшә. Чыннан да, яшьләрне нәрсәгә өйрәтә, нинди максатка берләштерә ул оешма? Кайбер районнар мисалында бу сорауга шактый анык җавап бирел була. Әйтик, балтачлылар мисалында. Бу районның Яшьләр оешмасы җитәкчесе Гамил Гыйбадуллин белән без еш очрашабыз - былтыр гына вуз бетергән егет Казанны онытып бетерми, килгән саен диярлек редакциягә сугыла. Үзе беркайчан да буш кул белән кермәс, йә кызыклы яңалыгы, йә тәҗрибәле журналистларның да башына килмәгән берәр идеясе булыр. Әнә, бу юлы да шулай: дискотекалар хакында сүз кузгатты. Дискотека дигәннән, күрмәгән нәрсә түгел - караңгылы-яктылы залда яшүсмерләр җыелышып сикерә торган заманча *тамаша* ул. Урысы да, татары да чит ил музыкасына бииләр анда гадәттә. Гамил бу юлы да шаккатырды:

- Балтачта дискотекалар татарча уза, - ди. Әле өстәвенә, һәр дискотеканы үзенә күрә бер темага багышлыйлар икән. Әйтик, күптән түгел Нардуган бәйрәме хөрмәтенә мәктәпләрдә һәм авыл клубларында дискотекалар уздырганнар.

- Иң күңеллесе - район үзәгендә булды, - ди Гамил.

- Татарча дискотекага ярардай музыканы каян табасыз соң? - дип сорыйбыз.

- Безнең яшьләр "Айфара" ансамбле кассетасына биергә ярата. Ә шулай да иң яраткан көйләре - үзебезнең Балтач авторлары иҗат иткән "Аулак өй" һәм "Озын толым" дигән җырлар. Үзебезнең "Нур" группасында җырлаучылар да - дискотекага йөрүчеләрнең уртак танышлары, дуслары, бәлки җырлары шуңа да бик якын тоеладыр.

Әгәр дә Гамил турында сездә, дискотека "җене" кагылган бер җилбәзәктер инде, дигән кебегрәк фикер туса, шунда ук "әстәгъфирулла!" дип әйтегез, чөнки ул (нәкъ киресенчә!) бик тирән фикерле төпле һәм белемле егет. Ә дискотекалар ясап мавыгуы - бүген-иртәгә туган телдән, татар моңыннан ваз кичәм дип йөрүче яшьләрне бергә туплау өчен, аларда милли горурлык уяту өчен. Заман баласы буларак, Гамил яшьләргә аңлаешлы һәр күренешне - сәнгатьтәме ул, гадәти тормыштамы, әллә күңел ачу чарасындамы - үз максатына хезмәт итә торган корал итеп файдаланырга тырыша. Үзенә күрә идеологияме? Бәлки шулайдыр. Коммунистик диктат чоры идеологиясенең үз чаралары булган кебек, ни өчен милли идеологиянең дә ышанычлы чаралары булмаска тиеш әле? Әгәр ул идеология үз йөзеңне, табигый җирлегеңне табарга булыша икән - бигрәк тә.

Балтачына кузгалыр алдыннан, Гамил безгә бер яңа идея бүләк итте:

- Әйдәгез әле, "Татарстан яшьләре" белән бергәләшеп татарча дискотекалар базары үткәрик! - диде ул. - Оештыруны үз өстебезгә алабыз, ә пропагандасы, яшьләрне һәм диск-жокейларны "котыртуы" - сездән...

Ә сез бу тәкъдимгә ничек карыйсыз, дуслар? Бәлки мондый күңелле эштә азмы-күпме тәҗрибә туплаган төбәкләрдән хатлар язарсыз? Теләк-тәкъдимнәрегезне "Балтач базары" дигән девиз белән җибәрегез. Жюрида кемнәрне күрергә телисез - шуны да язарга онытмагыз. Кыскасы, биибез!

**Флюра ГЫЙЛАҖЕВА.**

## Укыдыгызмы, ишеттегезме...

***Башкортостан*** төрмәләренең берсендә ятучылар, качарга уйлап, җир асты юлы казыганнар. Әмма юл аларны нәкъ чәнечкеле тимерчыбык каршына ук алып чыккан. Сакчылар, күреп алып, ут ачканнар. Качучыларның берсе үтерелгән, башкаларын тотканнар.

***Грузия*** Төркиядән 50 млн.доллар кредит алачак, дип белдерде Грузиянең тышкы эшләр министры Александр Чиквиадзе.

***Ереван*** шәһәренең атаклы Ботаника бакчасы агачларына тәмам киселеп бетү яный.

Салкын өендә бәрешеп утырып явызланган кеше, бу агач дөньяның әллә кай төшеннән монда күчерелгән, дип тормый шул. Бу хәлләргә чик куйса, властьларның каты кулы гына чик куя ала. Шулай булмаганда, Ботаника бакчасында корыган төпләр генә утырып калуы да мөмкин.



## М.Шәймиев Россия белән Татарстан арасындагы бозның кузгалуы турында хәбәр итте

Президент М.Шәймиев җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы делегациясе Мәскәүдә булып узган сөйләшүләрдән соң матбугат конференциясе үткәрде.

- Сөйләшүләр яңа баскычка күтәрелде - хәзер делегацияләрне ике яктан да президентлар җитәкли, - дип белдерде М.Шәймиев кереш сүз барышында. - Очрашулар алга таба айга бер, ә кирәк булганда ике мәртәбә үткәреләчәк. Үткән очрашу искиткеч ихтирамлы шартларда узды.

Конференциядә түбәндәге сорауларга ачыклык кертелде.

- Россия җитәкчелеге Татарстан теләгән зур хәрефтән языла торган Килешүне булдырмас өчен сөйләшүләрне махсус сузамы?

- Россия җитәкчелегендә Татарстанга карата иске стереотип карашлар өстенлек итте. Хәзер аларда аңлау сизелә. Килешү бары тик зур хәрефтән языла торган гына булырга тиеш.

- Килешүгә кайчан кул куелыр?

- Кул куюның акылга яраклы вакыты - апрельдә үтәчәк Россия референдумына кадәр.

- Россия Куркынычсызлык министрының Татарстан КГБсы коллегиясендә катнашуын ничек аңлатасыз?

- Беренчедән, Баранников безнең якташыбыз, икенчедән, ул бирегә сөйләшүләр барышында каралачак куркынычсызлык мәсьәләсен тикшерү өчен дип килде. Алга таба сөйләшүгә кертелгән мәсьәләләр буенча Россиянең башка министрлары да киләчәк.

- Татарстан егетләре "кайнар ноктага" җибәреләчәкме?

- Юк, анда бары тик теләге булганнар контракт белән генә барачаклар.

Журналистлар төпченеп алган кайбер мәгълүматлар:

- килешүдә каралачак куркынычсызлык, эмиссия (акча чыгару), салым, бюджет, милек һәм башка мәсьәләләр иң элек ике республиканың хөкүмәт җитәкчеләре дәрәҗәсендә тикшереләчәк;

- килешү өчен җаваплы кеше итеп Россия ягыннан Кавказдагы конфликтны хәл итү өчен хәрби кием киеп алган мәгълүм С.Шахрай билгеләнгән;

- Татарстанның тышкы экономик эшчәнлеге алга таба да дәвам итәчәк, озакламый республикага якындагы чит ил делегацияләренең килүе көтелә;

- үткән елның ноябрь аена Татарстанда хезмәт хакының үсеше Россия белән чагыштырганда 24 проценттан артыграк булган;

- базарга йомшак керү үзен аклаган һәм бу сәясәт февраль аенда да дәвам итәчәк;

- Татарстанда декабрь аенда авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү үткән елның шул ук вакыты белән чагыштырганда 10-12 процентка арткан;

- М.Шәймиев Россия ваучерын алган, ләкин әлегә эшкә җикмәгән.

**Миңназыйм СӘФӘРЕВ.**






Милли Мәҗлес Россия Югары Советының милли мәсьәләләр буенча комитетына мөрәҗәгать кабул итте. Анда Ульяновск шәһәре хакимиятенең татар халкы ихтыяҗларын чагылдыручы милли хәрәкәткә карата кулланылган законсызлыклар турында әйтелә, өлкәдә гомер бакый булмаган казак отрядлары оешып ятканда татар милли хәрәкәте органнарын һәрьяклап кысу, милли мәктәпләркең эшенә илтифатсызлык күрсәтү өлкәдә яшәүче татар халкын кыерсыту дип бәяләнә. Милли Мәҗлес Россия Югары Советын тагын бер милләтара ызгыш учагы китереп чыгармас өчен Ульяновск өлкәсендә халыкара хокук нормаларының үтәлешен тәэмин итәргә чакыра.

Чаллы мэриясе шәһәрне элеккечә районнарга бүлүдән баш тартты. Хәзер элеккеге ике район урынына 13 префектура оештырылды. Һәр эштән милләтчелек эзләргә тырышучылар префектура җитәкчеләренең ничәсе татар милләтеннән булуын да ачыкларга өлгергәннәр. Кызганыч, бу очракта чаң сугарга урын булмаган: 13 нең бишесе генә татар булып чыккан.

Халык телендә "кырыгынчы" дип йөртелгән дары заводы берничә айдан бирле кредитлар исәбенә генә эшли икән. Хикмәт - заказчыларның завод җитештергән продукция өчен түли алмавында. Аның каравы, биредә халык куллану товарлары җитештерү зур үсеш алган. Хәзер дары заводында эшләнгән арзанлы сагызны теләсә кайсы кибеттән алырга була. Балачага өчен моңардан да сөенечлерәк хәбәрнең булуы мөмкинме соң?!

Казан үзәк базары ролен үтәүче "Автомобилист" стадионына керү билетлары якын көннәрдә тагын да кыйммәтләнәчәк. Әйбер сатарга килүчеләр - 100, алырга теләүчеләр 25 сум түли башлаячак. Директорның аңлатуына караганда, бу чара базарның матди хәле авыр булудан эшләнә. Кемгә ничектер, әмма ачык һавадагы базарның да матди хәле булуы бик гаҗәпләндерә.

Комсомол йөрәкле яшьләр бүген дә бар икән әле. Дөрес, күп түгел - 20 кеше генә. Шуңа да, кворум җитмәү сәбәпле, Татарстан комсомол оешмасы конференциясе булмый калды. Әмма бу җыелыш тиз арада үткәрелмәсә, оешма таркалган дип исәпләнәчәк. Конференциягә килүчеләр соңгы срокны озайтуны сорап мөрәҗәгать иттеләр.



# Ваучерларны кая куярга?

Яз якынлашкан саен бу сорау үзенә тизрәк җавап бирүне көтә. Тик хәзергә әле бу сораугa анык кына берәү дә җавап бирә алмый. Сәбәбе - ваучерлар кабул итә торган махсус урын юк. 19 октябрь көнне теркәлгән, беренче һәм хәзергә әле бердәнбер булган махсус "Белем" хосусыйлаштыру инвестиция фонды исә бүген республикада үзенең эшчәнлеген киң колач белән алып бара. Фондның акцияләре теләгән һәрбер кешегә сатыла. Ә халык мәгарифе, мәдәният һәм сәламәтлек саклау өлкәсендәге кебек керемсез тармакларда эшләүчеләр өчен өстенлекләр дә каралган. Алар бер ваучер һәм 400 сум акчага 10 акция сатып ала алалар. Әлеге тармакларда эшләмәүчеләр шул ук бер ваучер һәм 400 сум акчага 8 акция сатып алырга хокуклы. Фонд Татарстан нефтехим комплексының хосусыйлаштырылган предприятиеләре, башка зур оешма һәм акционерлык җәмгыятьләре белән килешүләр төзегән. "Белем" фондының акцияләре эшчеләргә генә түгел, ә бәлки студентлар һәм пенсионерларга да сатыла. Акционерлар өчен дивидентлар 1994 елның беренче кварталыннан бирелә башлый. Республикабызның күп кенә районнарында фондның бүлекчәләре эшли. "Белем" фонды Казан шәһәренең Горький урамындагы 29 нчы йортның 19 нчы бүлмәсендә урнашкан. Мөрәҗәгать итү өчен телефон: 36-76-22.

Рәсемнәрдә: "Белем" фонды урнашкан йорт һәм анда эшләүчеләр.

**Е.КАНАЕВ фотолары.**



Фермер уйланулары

# Безгә берләшергә кирәк

*Татарстанда фермерлар ассоциациясе (ТФА) оешканга ике ел вакыт узды. Бу язмамда мин аның шушы чор эчендәге эшчәнлегенә тулы анализ ясарга җыенмыйм. Ләкин үзем дә шул казанда кайнаган кеше буларак, ассоциациянең кемгә һәм ни дәрәҗәдә кирәклеген билгеләүне бурычым дип саныйм. Язмам фермерлык турында гына да түгел, ә авыл хуҗалыгындагы кайбер бәхәсле проблемаларга кагыла.*

Бүген фермерлар Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы чакыруы буенча башкалага җыелдылар. Чынлыкта аларны Татарстан фермерлар ассоциациясе чакырырга тиеш иде бит. Ләкин республикада фермерларга булышлык итә торган андый оешма бармы соң ул? Элегрәк министрлыкта шәхси ярдәмче хуҗалыклар һәм бакчачылык ширкәтләренең эшчәнлеге белән шөгыльләнүче махсус бүлек бар иде. Бүген фермерлык хәрәкәте тулаем шушы бүлек кулына тапшырылды. Бүлекнең исеме генә алыштырылды. Хәзер ул "Эшмәкәрлек һәм игенче хуҗалыкларының яңа формалары бүлеге" дип атала.

Министрлыкка кабат әйләнеп кайтыйк. Шулай да ни өчен җыя ул бүген безне? Узган елның нәкъ шушы вакытында уздырган фермерлар җыелышы искә төшә. Дүрт сәгать буе министрлык чиновниклары ул чакта да юкны бушка әйләндереп сафсата сатканнар иде, быел да фермерларның кадерле вакытларын әрәм итү өчен генә чакырмыйлармы? Шушы урында тукталып, безнең республика ассоциациясен башка фермер оешмалары белән чагыштырып күрсәтер идем. Россия фермерлар ассоциациясенең өченче съездын гына мисалга китерәм. Хөкүмәт җитәкчеләре алдында төрле регионнардан килгән фермерлар үзләренең иң авыртулы проблемаларын, Югары Советка һәм югары органнарга булган киңәш-үтенечләрен, тәкъдимнәрен сөйләгәннән соң гына еллык эшнең нәтиҗәләрен тыңладылар. Аның каравы, фермерны нәрсә борчый, аңа нәрсә җитми, кайда кем аяк чала - боларның барысы турында да югарыдагы җитәкчеләр үз колаклары белән ишетеп белделәр. Ә Татарстанда киресенчә - кулына эш коралы тотып эшләүче фермерны, аның ничек җәфа чигүе турында тыңлаучы юк. Аннары министрлыктагы урындыктан ТФА урындыгына күченеп утырган чиновник-җитәкче элеккеге гадәт буенча советка да кандидатларны үзе тәкъдим итте һәм алар бертавыштан сайланып та куелдылар. Димәк, ассоциация җитәкчесе кубызына биергә әзер торучы "эшлекле" идарә органы туды һәм әлеге чиновникның кулына килеп керде дигән сүз. Шушы "тыңлаучан" советның карары белән былтырның ноябрендә генә дә республикадагы барлык фермер хуҗалыкларына тиешле финанс средстволары аерым фермерларга гына бирелде. Гаделме карармы бу?

Әйе, урындык - ул хакимият. Ул бөтен нәрсәне үзе хәл итә. Сайлап куелган совет та хаким сүзеннән ерак китә алмый. Бу - безнең системаның хакыйкате. ТФА оешканнан бирле мин фермерлык хәрәкәте белән кичәге аппарат чиновнигы түгел, ә гадел совет идарә итүенә ирешү өчен көрәшеп азаплакам. Менә шушындый совет ике ел эчендә минем һәм хезмәттәш фермерларымның никадәр көчен, мораль һәм матди байлыгын, ярты киләчәген тумас борын юк итте. Мин, мәсәлән, үземә тиешле кредитымны ике сезон буе ала алганым юк. "Файдасы" шул: җелеге суырылган җирләремне ике ел буе тәртипкә китерә алмыйм, төзелеш эшләрем башланмаган килеш, чыгымнар арттканнан-арта тора, ә уңыш, кызганычка каршы, үзеннән-үзе генә үсми шул. Башкалар да шуны ук әйтерләр. Ә бит ТФАга фермер хуҗалыклары өчен Рәсәй хөкүмәтеннән елына берничә мәртәбә финанс ярдәме алынып тора. Былтыр җиде ай эчендә генә дә ул 120 миллион сум бирелде. Ул акчалар һәр фермерга, аның һәр гектар җире өчен билгеле бер күләмдә бүленергә тиеш иде. Кая соң ул акчалар? Сере шунда. Әйтик, һәр фермерга 100әр мең сум кредит килде ди. Бу сумманы ул банкта гарант рәвешендә калдырып тора. Һәм банк фермерга аны берьюлы 500 мең сум итеп бирә ала. Рәсәйдән килгән һәрбер "өлеш"не фермерга әнә шулай файдалы юл белән кулланырга мөмкинлек туар иде. Ләкин ТФА җитәкчесе алай вакланып тормый, үзенчә эшли. Ягъни язын бер кешегә, калган дүрт кешегә тиясе өлешне дә кертеп, берьюлы 500 мең сум итеп бирә дә тегеләрне гел өлешсез калдыра. Шуңа күрә дә Татарстан фермерлары арасында банкротлыкка чыгучылар рәсәйнекеләргә караганда күбрәк. Ләкин ТФА советының бу кредит суммаларының кемгә, кая, күпме китүе турында безнең алда исәп-хисап ясаганы да булмады. Иманым камил, кемнең җирләре яхшы, иң зур кредитны да шулар алды. Чөнки мөнбәрләрдән торып сөйләү өчен "маяк"ларны элек-электән шул ук аппарат чиновниклары үзләре тәрбияләделәр.

Районнарда фермерларга ярдәм итү өчен министрлык каршындагы махсус бүлекләр оештырылган. Алар күпмедер дәрәҗәдә эш башкаралар. Ә бу "ярдәм" бер үк вакытта ТФАның эше дә булып тора. Чөнки, министрлыкның игенче хуҗалыклары белән эшләү бүлеге шул ук ТФА җитәкчесенең командасына буйсына. Фермерлар ассоциациясенең формаль рәвештә төзелгәнлеге менә шуннан аңлашыла инде. Аның каравы, бүлекнең тормышы яхшырды: хәзерге вакытта фермер хуҗалыклары өчен бюджеттан өстәмә средстволарны бүлеп алу бик җиңелмени? Техника бәясе арзан чакта заводтан яксә берәр колхоз, совхоз өлешеннән эләктереп калып була иде. Ә бу - министрлыкка баш иеп бару дигән сүз.

Фермерларга үз эшләрен уңышлы алып бару һәм банк алдында исәп-хисап тоту өчен бизнес-план кирәк. Шуның нигезендә генә банк алар белән үзара килешү төзи. Мондый бизнес-планны колхоз-совхозлар өчен Татарстан җир предприятиесе эшләп бирә. Ләкин бу предприятие минем өчен, ягъни фермер хуҗалыгы өчен андый планны төзи алмады. Чөнки фермерлык һәм җир кодексы законнарының "пешеп" җитмәгәнлеге ачыкланды. Ә бит ул закон проектларын, гәрчә фермерлар дөрес юнәлеш бирсәләр дә, белгечләр һәм фермер оешмасы җитәкчеләре эшләгән, Югары Совет аны кабул иткән, Президент шуның буенча указ чыгарган. Мәсәлән, Татарстанда фермер хуҗалыкларына бирелгән җир участогы 1 кешегә уртача 37 гектар туры килә. Сөрү җире аннан да азрак. Нәтиҗәдә продукция җитештерүдән бары тик зыян килә. Әйтик, ун гектардан уңыш үстереп алу өчен 600 гектарда үстергәнгә караганда ике мәртәбә күбрәк чыгым тотыла. Өстәвенә, табышның (әгәр ул булса) дүрттән бер өлеше банктан алынган ссуданы каплауга һәм процентларны түләүгә китеп бара. Бу - закон буенча! Тагын шунысын да әйтергә кирәк, фермер хуҗалыгы өчен иң начар, ташландык, авылдан ерак урнашкан җирләрне бирергә тырышалар. Җитештерелгән продукциянең узкыйммәте үзеннән-үзе 2-5 мәртәбә югары була дигән сүз. Бу да гамәлдәге законнар нигезендә эшләнгән! Үземнең җирләремне мисалга китерә алам. Уңдырышлылыкны торгызу өчен иң элек участоктагы туфракның сыйфатын зур төгәллек белән тикшерергә кирәк булды, аннары тиешле күләмдә, фосфор, доломит оны кертергә (гектарга 12 тонна исәбеннән) кирәклеге ачыкланды. Туфракның гумусы, ягъни уңдырышлы катламы нибары 1,2-1,4 процент калган (ә ул норма буенча 3-3,5 булырга тиеш). Шушы эшләрне башкарып чыгу өчен генә дә бер җәй вакыт көчкә җитеп калды. Әле ярый, совхоз биргән мәгълүматларга ышанып, беренче елны ук иген чәчүгә керешмәгәнмен. Күпме хезмәтем әрәмгә китәр иде. Закон буенча исә фермер бөтен характеристикасы күрсәтелгән участокны кабул итеп алырга һәм беренче елны ук уңыш үстерергә тиеш. Һич тә дөрес нәрсә түгел бит бу. Рәсәйдә җирне тулаем тәртипкә кертү өчен фермерга өч ел вакыт бирелә. Ә бездә ике елдан бирле уңыш үстермисең дип, участокны кире тартып алу белән куркыталар. Менә шулай итеп, фермер бер яктан, авылдан ерак - басу эчендә урнашкан участогына барырга, шул юлларда ватылган техникасын ремонтлатырга, ягулык-майлау материалларын ничек юнәтергә белмичә тилмерсә, икенче яктан, җирләрен яхшыртырга вакыт һәм финанс җиткерә алмый аптырый.

Законнарда тагын бер хикмәт бар. Аннан күренгәнчә, фермерның өстәмә керем чыганакларыннан файдаланырга хакы юк. Ә бит мондый мөмкинлек участокны үзләштергән һәм хуҗалыкны ныгыткандан соң чакта бигрәк тә файдалы булыр иде. Чит илләрдәге фермерлар нәкъ менә шундый юл белән аякка басып китәләр. Безнең Конституция буенча да бу мөмкин, әлбәттә. Әмма тагын капма-каршылык: фермер хуҗалыклары турындагы закон буенча бу эш ярамый. Димәк, ике закон проектын ике кеше: берсен - депутатлар, икенчесен авыл хуҗалыгы министрлыгы чиновниклары бер-берсе белән килештермичә эшләгәннәр һәм... фермер эшчәнлегенә таяк тыкканнар.

Янә җиргә төшик әле. Фермерлыкка ныклап тотыныр алдыннан, мин Кубань авыл хуҗалыгы академиясендә курсларда укып кайттым, үзлегемнән белем күтәрдем, совхозда экономист булып та эшләдем. Кыскасы, авыл хуҗалыгы өлкәсендә шактый тәҗрибә тупладым дисәм дә ялгышмам. Ләкин колхоз, совхоз системасыннан киткәч, җиңел сулыш алып куйдым. Чөнки кыска гына вакыт эчендә әлеге тармактагы җавапсызлык, тәртипсезлек күренешләре белән аз очрашырга туры килмәде. Бигрәк тә туфракның әрәм-шәрәм ителүенә җан сыкрый иде. Туфрак бит ул - нефть белән бер, ул - милли байлыгыбыз. Нефтьне суыртып бетереп булган кебек, туфракны да юкка чыгарырга мөмкин. Һәм аны юкка чыгарганнар да! Бу - игенчеләрнең үз куллары белән җитәкчеләр, белгечләр ярдәмендә башкарылган. Әлеге "җир хуҗалары" бүгенге көн белән генә яшиләр. Бүген ашарга икмәк булса - шул җиткән, иртәгәсе өчен ишәк кайгырсын дип фикер йөртүче түрәләрнең нинди югары белемгә ия икәнлекләрен аңларга мөмкиндер. БМО каршындагы Халыкара авыл хуҗалыгы оешмасы (ФАО) мәгълүматларына караганда, нормаль шартларда уңышның 80 проценты туфракның сыйфатына, бары тик 20 проценты гына бүтән факторларга бәйле икәнлеге билгеле. Ә менә бу саннарны соры урман туфраклы басуларга күчереп исәпләсәң, мин һәр гектардан нибары 7,2-8,4 центнер уңыш ала алам. Менә шуннан фермер хуҗалыкларына булган мөнәсәбәт турында сөйләп кара инде!

Авыл кешеләренең күбесе коллектив хуҗалыкны бетермәү ягында. Ни өчен? Чөнки фермер - ул эшмәкәр, малтабар. Алар авылда бик аз. Бизнес, хуҗалык эшчәнлеген сәнгать белән тиңләр идем мин. Моның өчен тумыштан килә торган сәләт, осталык, профессиональ белем кирәк. Ә колхозчы озак еллар дәвамында мөстәкыйль хуҗалык итә белү сәләтен бөтенләйгә югалткан, хуҗа нәрсә куша, ул шуңа һичсүзсез буйсынырга күнеккән. Уйлап, хисаплап, борчылып баш ватасы юк, бу эшләрне башкаручы махсус кешеләр бар бит. Шуңа күрә авыл халкы колхоздан аерылырга теләми дә.

Ә үзе, эше, киләчәге турында уйлый башлаган бүгенге фермерлар барысын да үзләре кайгырта. Ә бу ансат кына бирелми. Шуңа күрә мин фермерларга киңәш йөзеннән берничә конкрет фикеремне дәлилләп аңлатасым килә. Иң элек безгә, фермерларга, үзебезнең беркемгә дә буйсынмый торган югары органыбызны - чын ассоциациябезне булдыру кирәк. Бәлки ул бүгенге кәгазьдәге ТФАга альтернатива рәвешендә оешыр. "Российский фермер" фондыннан кредит алу мөмкинлеге хәл ителгән, АККОР безгә ярдәм кулы сузарга әзер. Яңа ассоциацияне хуплаучы көчле фермерларыбыз аз түгел. Устав эшләнгән. Кредит проблемаларын хәл итәргә әзер торучы банк та, страховка компаниясе дә бар.

Фермерларның бүгенге республика киңәшмәсе уңае белән мин менә шушы фикерләремне җиткерергә теләгән идем. Әгәр минем белән килешмәүчеләр яки тагын да кызыклы һәм файдалы уйхыяллар белән яшәүчеләр булса, аларны да бик рәхәтләнеп укыр идек.

**Госман МИҢЛЕБАЕВ,**
фермер.
Татарстан фермерлар ассоциациясенең совет әгъзасы.
Пктрәч районы.

Әйтик, кибетче "бармагын кушып" сатты, коммерсант дәүләт налогын ким түләде, администратор үзенең бухгалтеры белән бергә ялган документ тезеп акча үзләштерде, ди. Боларның барысын да, бәяләрне ычкындырып, ясалма тудырылган базар мөнәсәбәтләре таләмәте дип аңлатыйк. Әмма кайсы кибетче, коммерсант, администратор, бухгалтер үз балаларын гаиләдә, ә укытучылар мәктәптә, җинаятьче итеп тәрбияләргә тырышыр икән. Шикләнмим, һәрберебез үз баласын таза-матур, белемле, намуслы итеп күрергә тырыша. Ә нигә киресе килеп чыга? Моның сәбәбен, беренче чиратта, мәктәпнең белем-тәрбия бирү системасыннан эзләргә кирәктер.



# Черек мәгариф һәм мескен балалар

Чын педагогикага нигезләнгән халык мәгарифе тумас борын җирләнде. Аның урынын "совет" исеме астындагы тоталитар режимның партия мәгарифе алды. Хәзерге вакытта бу мәгариф яшәп килә генә түгел, ә үзенең позицияләрен ныгыта гына бара. Миңа еш кына, элек тә шушы мәгариф яшәде бит, ә мондый хәл юк иде, дип каршы төшәләр. Ә 42,5 миллион аттырылган, репрессияләнгән шәхесләрне, сугыш кырында дошманга караганда 3 тапкыр артык - 19 миллион кеше югалтуыбызны, бетүгә дучар ителгән халыклар язмышын, телен, тарихын, гореф-гадәтләрен югалтуга йөз тоткан татарлыгыбызны кайсы кысаларга сыйдырырга? Бу педагогиканың нигезендә идеяне (ялганын да, чынын да) фальсификациягә барып булса да, раслау һәм аңа аллага табынган кебек инандыру ята. Ни өчен укучыларыбыздан "һәрьяктан гармонияле үскән кеше", бер тамчы су кебек охшаш детальләр ясап чыгарырга омтылуыбызны һаман дәвам итәбез. Муштра астында гына атларга өйрәнгән "прусс солдатлары" заманы узды түгелме?

Кеткән, вәгъдә ителгән коммунизмның тиз генә килмәвен, тулысынча һәм тәмам җиңгән, нык үскән социализмның бары тик кәгазьдә генә тудырылуын яшьләр инде 60-70 елларда ук аңлый башладылар. Җитмәсә, бу чорга сыйнфый дошманнары да бетеп китте, ә бу власть үз иле эчендәге кешеләрне үзара сугыштырып кына яши ала иде бит. Нәтиҗәдә, дошман образы урамнарга, клубларга, мәктәпләрнең үзенә дә күчте. Җинаять үскәннән-үсә барып, дәүләтнең асылына әйләнде. Ә фәннәрне исә балалар ятларга теләмәделәр, билгеләр, шушы кысаларда гына булса да, реальлеген югалтты. Аның карабы, процент артыннан куып, югары билгеләр куя-куя һәркемне физик, химик, математик, тарихчы, филолог, рәссам, музыкант "ясауны" дәвам иттердек һәм иттерәбез. Укучыларның белемле дип саналганнары да, нигездә, сорауга җавапны чит кеше киңәшләре, китап фикере аша гына бирә алалар. 2 гыйнвар көнне "Могҗизалар кыры" тапшыруын караган булсагыз, балаларның үз туганнарына, иптәшләренә сәлам тапшыруларына игътибар иткәнсездер. Брежнев, яисә Горбачев докладын башының күчермәсе" дип белерсең. Ник бер конкретлылык, шаярту булсын.

Тәнәфес вакытында башлангыч сыйныф укучылары янына килдем. Кыш турындагы текстны укып изложение язып азапланалар. Ә урамда чын кыш! Соң шул ук балаларны мәктәп янындагы бакчага алып чыгып, кышкы табигатьнең бизәкләрен, күренешләрен аңларга өйрәткәндә, алар бит сочинение дә яза алган булырлар иде. Чит кеше текстын механик хәтердә калдырган изложение түгел, ә үзләренең ачышларын, иҗат җимешләрен кәгазьгә төшергән булырлар иде. Укучыларның татар теле, рус теле дәресләрендә күп вакытлары грамматика ятлап, аларга грамматик анализ ясап, укытучы иҗекләп әйтүдән диктантлар язып уза. Нәтиҗәдә, күпчелеге урта белем белән дә адәм рәтле яза да белми чыгалар. Татар әдәбияты, рус әдәбияты дәресләрендә укыганны сөйләүдән, яртылашын китаптан күчереп, сочинение язудан ары уза алмыйлар. Ирекле сочинениеләрдәге фикер сайлыгын күреп таң каласың. Кая ул Лев Толстой белән Максим Горький, Габдулла Тукай белән Дәрдмәнд әсәрләренә чагыштырма аңлатма бирә белү! Тарихны исә хәзер яшәп килә торган дәреслекләр белән укыту - җинаять! Аларда сыйнфый көрәш идеологиясе, дошман образы тудыру ярылып ята бит. Ялганы, чыны белән теорияне исбатларга мәҗбүр итүче партия педагогикасын кайчан чүплеккә ыргытырбыз? Кайчан практик эш, күнекмәләр аша укучының эшчәнлегенә юнәлеш бирү, фикер йөртү сәләтен үстерергә ярдәм итеп, аның теге яки бу мәсьәлә, вакыйгага үз карашын булдыру юнәлешендәге дәреслекләргә ия булырбыз? Дерес, яңа дәреслекләр төзү өстендә эшлиләр дип ишеттем. Әмма алардан артык күп нәрсә өмет итмим. Ни өчен иканлеген аңлатып, үземә бихисап күп яңа дошманнар тууын теләмим. Гафу итегез! Кем әйтмешли, яшәрбез, күрербез, мөнәсәбәтебезне белдерербез. Ә "Мәгариф" журналында бу мәсьәләне тикшерү иң зур урын алырга тиеш, минемчә. Иң борчыганы шул, әлегә кадәр татар тарихы буенча дәреслек юк. Край тарихы әлегә 5 нче сыйныфта гына өйрәнелә. Әллә һаман рус милләтчелеге кысаларына сыйдырылган "совет" халкы тарихын өйрәнүне дәвам иттерергә исәплибезме?

Ачыла торган гимназияләребез - әчтәлеге ягыннан шул ук мәктәпләр. Бу уңайдан үз фикеремне әйтим. Җиде-сигез ел гомуми белем, тәрбия бирү мәктәпләреннән соң аеруча талантлы балалар өчен аерым фәннәрдән махсус колледжлар ачу кирәктер. Ә калганнары өчен мәктәпләр базасында һөнәргә өйрәтү системасы кертү гамәлгә ярашлы булыр.

Уку-укыту, тәрбия бирү процессы тоталитар режим педагогикасы нигезендә алып барылганда укытучыларны аттестацияләү, категорияләргә бүлүгә дә карашым тискәре. Хәер, аны алып бару процессы нәкъ шул эз белән бара. Узган ел аттестацияләү тәртибе быелгысыннан үзгәргән иде. Укытучылар һәм укучыларга анкеталар тапшырылды. Мисал өчен кайбер сорауларны китерәм:: оригинальность, принципиальность, работоспособность, честность, отношение к коллегам и товарищам һ.б. (Татарчага тәрҗемә итмәдем, чөнки күбесен тәрҗемә итеп булмый). Укучы укытучыга бәя бирә ала икән, ул вакытта укытучының кирәге дә юк бит. Менә сезгә демократия! Быел инде соңгы сүзне администрация әйтә. Кызык, әгәр ул администратор икән, димәк, барыбыздан да акыллырак, эшлеклерәк дигән сүз. Аттестацияләү тәртибеннән диктатура исе килә. Шикләнмим, укытучыларны сугыштыру алымы бу. Кан исе килергә дә ерак түгел. Ельцин указы чыгып та җитмәде - менә сиңа мә! Санаулы көннәр эчендә укытучыларны категорияләргә бүлеп тә куйдылар. Югарырак категория аласың килсә, калган гомереңнең тамчысына кадәр түрәләргә ялагайлан, "табак"тот. Эшләр болай торганда мөстәкыйль Татарстаныбызның мәгарифе "ышанычлы кулларда", булуына шикләнмим. Укытучы эшен бәяләүдә бердәнбер таләп - укучыларның белем дәрәҗәсен билгеләү һәм укытучыларның башка өлкәләрдәге эш күрсәткечләре. Җиһазланган кабинет булуын һәм фәнни-методик эшне күз алдында тотып әйтүем. Югарыда язылган фикердән чыгып, әле бу таләпләр өчен шартлар өлгермәгән дип саныйм. Ул чагында эш стажын, белемен исәпкә алып, хезмәт хакын билгеләргә генә кала.

Ильяс ГАРИПОВ.
Балык Бистәсе районы,
Олы Әшнәк урта мәктәбенең
тарих укытучысы.

## Игелеклелек мәңгелек

Кеше белән тулы бу җиһанда да ялгызлыктан гаҗизләр бар. Игътибарга, назга, ниһаять, үзенә атап, нәкъ аның үзенә генә атап әйтелгән бер җылы сүз ишетергә тилмереп яшәүчеләр. Редакциягә килгән бер апаның сөйләп утырганы хәтердә: "Беркемем юк. Атналар буе бусагамны атлап ник бер адәм заты керсен. Песи генә йөри. Ичмасам, көн саен капкамны ачып керүче булыр дип язылдым газеталарга да..." Авыл җирендә яшәүче бер ана сөйләде моны. Баксаң, әле аның кияве, кызы, оныклары да бар икән. Гаҗәп тоеламы? Авыл җиренә хас түгел дисезме? Ә бәлки, очраклы бер күренеш кенәдер бу? Терлесен уйларга була. Ни дисәк тә үз ихтыярыбызда. Нишлисең, бер очрак кына булган хәлдә дә, кеше язмышы турында сүз бара бит. Ялгызлык. Нәрсә соң ул? Нилектән кеше ялгыз? Сәбәпләре аның бихисаптыр. Минем максат аларны эзләү түгел иде әле. Хәтта өең тулы кеше булганда да кеше гомере буе ялгыз булып кала ала. Шул өй тулы кешеләрнең һәркайсының үз дөньясы, үз көе дигәндәй, ул шуның эченә бикләнгән, бүтәннәрдә аның гаме дә, эше дә юк. Үз эчендәгесен дә кем беләндер уртаклашырга җыенмый. Бу җәһәттән безнең бүгенге тормышыбыз аеруча катлаулы. Һәр тумыш көн адәм баласы алдына берсеннән-берсе катлаулырак мәсьәләләр куя. Чишә аласыңмы син аларны, ничегрәк, нинди юл белән? Болары турында үзең баш ват, үзең кайгырт. Ярый әле хәлеңнән килердәй вак-төяк кенә булса... Кайгы-хәсрәт белән ялгыз калудан ходай сакласын!

Ялгызлык - күңел халәте ул. Редакция почтасын укыганда бу халәт аеруча күзгә ташлана. Менә бит ялгызлыктан, якыннары белән аңлаша алмаудан алҗыган, шушы киң җиһанда үзен күптән кирәксез дип санаган, кайдандыр ярдәм көтүдән өмет өзгән бәндәләр азмыни? Редакциягә килгән хатларны укыганда нәкъ шул хакта уйлап утырдым. Ләкин, "нет худа без добра" диләрме әле. Инде дә тәмам чигенә килеп җиттем дигәндә, ходайның рәхмәте, кайдандыр бер җае чыга да куя. Бусына да мисал эзләп ерак барасы юк, редакция почтасы шаһит.

"Бердәнбер куанычым, тормыштагы бердәнбер ышанычым булган балам авырый. Табиблар аңарда дәвалап булмый торган чир - хроник лейкоз таптылар... Өзгәләнә йөрәк, әмма күңелдә өмет тә яши. Ә бәлки... Каштан чәчәкләре шифалы дигәннәр иде. Экологик чиста урыннардан җыйган каштан чәчәкләре киптереп җибәрүчеләр булса, акчасыннан тормас идем..."

Укучыларыбыз хәтерлидер, газетабызның узган елгы 43-44 нче саннарында чыккан иде бу хат. Шуннан соң атна-ун көн үттеме-юкмы, адрес сорап, ярдәм итәргә теләп хатлар агыла башлады. Телефоннан шалтыраттылар. Хәтта ярдәм посылкасы редакциягә үк килеп җитте.

Шушындый фидакарьлек каршында ничек баш имисең. Донецк каласыннан Рауза апа иң беренчеләрдән булып ярдәмен тәкъдим итте, аннан тагын күпләр.

"Улымның хәле әйбәтләнеп китте. Кешеләрнең игелеклелегеннән үземнең дөньяга ышанычым артты", - диде игелекле бу кешеләргә тирән рәхмәтен белдерергә дип редакциягә килгән әлеге ана.

... Балык Бистәсе районыннан беренче группа инвалид өйдә йөрер өчен коляска таба алмавына бик борчылып хат язган иде. Күпмедер вакыт үткәч, ул кабат хат язды. "Миңа кайдан гына, кемнәр генә коляска 'тәкъдим итмәде, ниһаять, мин игелекле кешеләрнең ярдәмен тойдым. Бу үзе зур бәхет. Рәхмәт!"


"Улыма бәләкәй гармун кирәк иде. Беркаян табар хәл юк. Кайдан гына табарга икән?" "Авыл җиренә китеп яшәр идем. Ярдәм итүче табылыр микән?" "Дөньялар авыр, әйберләр кыйммәт. Мин әти-әнисез. Мәктәптә укыйм. Кыш җитә, өстемә кияргә кышкы киемем юк. Берәрсе миңа арзан бәягә тун тәкъдим итмәс микән?"

Болар - газетабызда чыга торган "13 нче багана" рубрикасында басылган хатлардан сайлап алынган кайбер юллар гына. Ышанасызмы, аларның берсе дә җавапсыз калмады. Ярдәмен, киңәшен я кирәкле адресын тәкъдим иткән хатлар дисезме, "Посылканы кайсы адрес белән җибәрим?" дип сорап килүчеләрме - игелеклелек адресларын, һәр конкрет кешенең фамилиясен-исемен санап китү генә дә байтак вакытны алыр иде. Хәер, мин андый максатны күздә тотмадым да. Иң сөендергәне - игелеклелек. Ул коры сүз генә түгел. Игелеклелек - кешенең эш-гамәле. Рас ул күңел ихтыяҗы икән, яшәргә була, ышанырга була. Рас ул күңел ихтыяҗы икән, андый кеше үзен күрсәтүгә мохтаҗ түгел. Тик без соңгы вакытта нигәдер игелеклелеккә, гаделлекнең яшәвенә ышанычны югалта башладык. Нигә икән? Әйтерсең лә, ул кайдадыр яшеренгән һәм дөньяга баш калкытырга кыймый. Үзебез дә ничектер сәерләндек, үз эчебезгә бикләнеп яшәргә күнектек. Күрше-күләнгә, дусларга, кая ул, хәтта якыннарыбызга ачылырга йөрәк җитми. Нигә икән? Нәрсә соң күңел биге булып тора? Үз кайгыбыз, үз уйларыбызда үзебез кайныйбыз. Башкалар кайгысына гамьсез булуыбыз да шуның нәтиҗәсе түгелмени? Ләкин ни генә дисәк тә, "тормыш көзгесе" - хатлар шуңа ышандыра: игелеклелек бетмәгән. Ул - мәңгелек. Дөнья шуның белән бизәлә. Менә бит, хатлар сөйләп тора. Газетабызның узган елгы 120 нче санында "Халык тавышы" рубрикасында Мөхәммәт ага Хәбибуллин үзенең уйлары белән уртаклашкан иде. "Йөрәк авыруы белән интегәм. Нитроглицериннан башка тора алмыйм", - дип язган иде. Юк, аның ярдәм сорап ялваруы түгел иде бу. Ләкин шулай да башкаларга ярдәм итүдән тәм тапкан укучыларыбызны аның бу хаты битараф калдырмаган. Шуларның тик берсенә тукталам.


"Мин Мөхәммәт абыйга дип күп итеп нитроглицерин даруы алып куйдым. Җибәрергә аның адресын белмим. Даруларсыз тилмермәсен иде. Адресыбыз: 678736, Якутская Саха, Оймяконский район, поселок Предпорожный. САМАТОВЫ".

Кызганычка каршы, Мөхәммәт аганың адресы бездә сакланмаган. Без аның белән телефон аша хәбәрләшкән идек. Әмма мин ышанам, ул безнең газетаны, үзенә адресланган бу юлларны укымый калмас.

Рика ЗАРИПОВА.







Гадел НИЗАМ

## Эт биюе

Яңа кардан урман исе килә,
Каен исе килә, нарат исе.
Әле яңа гына тынган буран,
Чистарган да куйган шәһәр эче.
Кар астында калган кара эзләр,
Зур каланың шакшы чүп-чарлары.
Кар эченнән бик гыйффәтле генә
Карап тора керле диварлары.

Көрттә аунап уйный бер йолкыш эт,
Ник кыбырсый икән сукбай җаны?
Кар астында гүя асфальт түгел,
Ә бер хозур кыргый эт яланы!
Каң хәтере эткә сурәт чигә -
Кышкы урман, алан, җанвар сынын,
Сәер биюендә кабатлый эт
Шат уенын бүре бабасының...
Яңа кардан авыл исе килә,
Хас авылча аның исе-төсе.
Эт җирсесә җиргә ятып ауный.
Миндә - эт халәте. Их, нишлисе!..

# Бүлгәләгән саен безне, Арта гына барабыз...

## Сабырлык солтаны

*Уфада гына түгел, Башкортостанның бүтән төбәкләрендә дә саф татар телендә иҗат итүче язучылар шактый. Аларның күбесе белән мин хатлар алышам. Гыйнвар аенда Фәрит Габдрәхимнең иҗади бәйрәме узачагы турында хәбәр алдым. Берничә көннән юбилярның үзеннән дә хат килеп төште. "Уфадагы Татар иҗтимагый үзәге минем юбилейны уздырырга теләгән иде. Башкортларның кәефе кырылыр дип, уздырмадым. Юбилей уңае белән шигырьләремне, Башкорт җирендә яшәүче татар шагыйре буларак, Татарстан матбугатында чыгарырга уйладым. Кереш сүз язарга ниятләвең өчен рәхмәт, - дип дәвам итә хатын Габдрәхим. - Алай бик зурдан кубарлык түгел иҗатым. Нибары алты китапчыгым дөнья күрде Уфада, алары да башкорт телендә. (Ә Казан һаман әле төшкә генә керә!) Уфада иманы камил татарга бер җыентык чыгару да - сират күперен кичү белән бер. Соңгы китабым 1991 елда чыгарга тиеш иде. Гайса Хөсәеневтән эчке рецензия дә яздырып алган нәшрият. Кульязмамны алып кайттым да бүтән илтмәдем. Ни гомердән Уфада яшим, гел татарча язам... ә ни өчен соң татар телендә дөнья күрергә ярамый Уфада татар китабына?! Башкортостанны үзләренең ватаны санаган һәм аңа тугрылыклы хезмәт итүче 1 миллион 120 мең татар халкын кая куясың?! Менә шул гарьләндерә җанны. Татарларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә каршылык бик көчле Башкортостанда. Уфада татар китап нәшрияты ачу турында Башкортостан Министрлар Советының махсус карары бар югыйсә. Ул карар да үтәлми калыр микән?.." Асылы белән керәшчә булса да, Фәрит Габдрәхим - гаҗәеп тыйнак, сабыр кеше. Ә шигърияттә - бик таләпчән, тынгысыз каләм остасы. Сирәк язса да, бәрәкәтле, төпле яза.*

*Имансызлар өчен - кылыч,*
*Тончыктыргыч ядрә син.*
*Безгә - сабырлык солтаны,*
*Тугры дус син, Габдрәхим!*

**Мәхмүт ХӨСӘЕН.**

## *Аркан*

Халкым! Муеныңда нинди аркан,
Түгел каеш, түгел җеп кенә.
Бу арканның очы, һай, еракта -
Мең дә биш йөз илле икедә.

Байракларның күрдең төрлеләрен:
Яшелен вә агын, кызылын...
Аркан гына һаман өзелмәде -
Бушады да кабат кысылды.

Тезләнәсең, хәтта чигенәсең,
Вакыт кына белми чигенә.
Сынып калган сөңге-кылычларың
Мең дә биш йөз илле икедә...

Киңлекләргә чабып китмәкчесең,
Йөрәккәең куя җилкенеп.
Әле һаман онытмадыңмыни
Мең дә бер йөз илле икене?!

Хуҗаң бага моңсу күзләреңә
Белмәк булып яшерен уеңны.
Дүрт гасырдан артык сызлый инде
Гел кансырап торган муеның.

Тагын ничә гасыр тотар икән
Тимер куллар аркан очыннан?..
Арканнарны өзәр тешләр кирәк,
Тешләләр ич өзә - ычкына.

## *Унбишенче кисәк*

Таралырга тора империя...
Челпәрәмә килеп беткәнче,
Коткарырга! -
Төнлә ил тәхетен
Басып алды сигез фетнәче.

Сигезе дә империя яклы,
Сигезе дә алды кочакка.
Сигезе дә утны сүндерәм дип,
Сипте бары бензин учакка.

Көне җиткәч, шартлый империя -
Шушы хакта тарих кисәтә.
Фетнәчеләр кочагыннан төшеп,
Ватылды ул унбиш кисәккә...

Безне кабат Сәмруг кошлы итү -
"Өлкән туганыбыз" исәбе.
Бабайлардан калган безнең өлеш -
Шул унбишнең иң зур кисәге.

Калтырансын татар дипме әллә,
Кыегына аны беркетә.
Унбишенче кисәк - империя...
Кирәк, ахры, тагы бер фетнә.

## *Җитмеш җиде тапкыр*

"Бүлгәлә дә хакимлек ит!" -
Бетерделәр бүлгәләп.
Без яшәргә тиеш идек
Билне бөгеп, чүгәләп.

Каердылар-аердылар
Җитмеш җиде кисәккә.
Ә нинди ул - татар җаны? -
Алмаганнар исәпкә.

Бүлгәләгән саен безне
Арта гына барабыз.
Ерагайткан саен безне,
Якыная арабыз.

Инде җитмеш җиде тапкыр
Без зуррак һәм көчлерәк.
Хакыбыз бар - тик булмабыз
Шул ук тапкыр үчлерәк.

Кулдан килә дусны җитмеш
Җиде тапкыр сөяргә.
Карагруһны шул кадәр үк
Баш аркылы чөяргә.

## *Сөендек*

Инкыйлаб! Ирек! -
Кәпәчләр
Күккә дәррәү чөелде.
Кызыл, ак төс. Башкасы юк.
Кызыл җиңде - сөендек.

Башлары һәм буралары
Буш түгелләр сөрелде.
Тигезләштек ярлылыкта,
И шуңарга сөендек.

Манаралар ауды. Диннең
Сүнмәвенә көендек.
Колхоз кордык. Җирсез торып
Калганга и сөендек.

"Милләт" сүзе бик күпләрнең
Бугазына төелде.
Татар булсак та, "папа"га
Әйләндек дип сөендек.

"Дуслык!" дидек. Күпме илләр
Тарафыннан "сөелдек".
Кайберәүләр бездән ярдәм
Алмасалар, көендек.

Без - алдынгы!
Булганы юк
Без чишмәслек төеннең.
"Егерме елдан - коммунизм!" -
Нинди бәхет! Сөендек!

Шаклар каттык, беткәч төрмә
Диварлары өелеп...
Көенәбез микән - элек
Яшәгәнгә сөенеп?



* * *

6-10 ваучерны Казан яки Зеленодольск шәһәрләрендәге фатирга алмаштырабыз. 2 ваучерны яңа "стенка"га алмаштырабыз.

Адрес: 420136, Казан-136, XV-КБ серияле, 699800 номерлы паспорт иясенә.

* * *

"ЗАЗ-968 м" автомобилен һәм 4-6 ваучерны "Москвич", "Жигули" яки башка җиңел машинага алмаштырам.

Адрес: 422950, Татарстан, Чистай шәһәре, Котовский урамы, 84. ПЕТРОВА.

* * *

Нарат агачыннан эшләнгән 9,5x9,5 метр зурлыктагы, түбәсе ак калай белән ябылган, 13,5 метрлы верандасы булган өйне яңа "Нива" яки "Жигули" автомобиленә алмаштырам.

Адрес: 452260, Башкортостан, Илеш районы, Үрге Яркәй авылы, М.Гәрәй урамы, 15. Мансур ШАКИРОВ.

* * *

6 ваучерны яхшы хәлдәге "Жигули", "Москвич", "Ока" яки яңа "Запорожец" автомобиленә алмаштырам.

Телефон: 3-25-95 (Чистай районы).

* * *

Октябрь аенда Казан автовокзалы тирәсендә "Малыш" исемле җонлач песи югалды. Бәлки, аны иясе юк дип алып киткәннәрдер. Табып китергән кешене бүләк көтә..

Телефон: 37-24-62.

* * *

80 данә тавык йомыркасы, 60 данә үрдәк йомыркасы, 35 данә каз йомыркасы сыйдырышлы инкубатор сызымын һәм чебеш чыгару технологиясен тәкъдим итәм. Инкубатор гади, сыналган, аны бер көндә ясап була. Заказлар 1 майдан соң кабул ителми. Үтәлү срогы - 1 атна. Заказ ясау өчен бланкта үзегезнең төгәл адресны күрсәтеп түбәндәге адреска 150 сум акча күчерергә һәм квитанцияне сызымнарны алганчы сакларга.

Адрес: 612900, Киров өлкәсе, Вятские Поляны шәһәре - 4. V-КБ серияле, 618528 номерлы паспорт иясенә.

## Котлыйбыз!

**Укучыларыбыз игътибарына!**

**Газетада котлау турында белдерү бастыру өчен редакция счетына 200 сум акча күчерергә һәм акча күчерү турындагы квитанция белән котлау текстын редакция адресына җибәрергә кирәк.**

* * *

Сарман районы, Рантамак авылында яшәүче кадерле әниебез Әнисә Фатыйх кызы һәм әтиебез Гомәр Әюп улы Кадыйровларга гыйнвар аенда 65 яшь, бергә тормыш итә башлауларына 40 ел тула. Кадерле әтиебез һәм әниебез! Сезне чын күңелебездән олы юбилеегыз белән котлап, корычтай нык сәламәтлек, бәхет, зур шатлыклар, балаларыгызның игелеген күреп, кайгы-хәсрәтсез, тыныч тормышта яшәвегезне, озын гомер кичерүегезне телибез.

Иң изге теләкләр белән: кызларыгыз, улыгыз, киленегез, кияүләрегез һәм оныкларыгыз.

**"Татарстан яшьләре" газетасы редакциясе, элеккеге мөхәррир Хәлим Гайнуллинның әтисе Абдулла Зиннәтулла улының вафаты сәбәпле, аның һәм туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.**




Баш мөхәррир урынбасары Миңназыйм Сәфәров (53-07-52)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2. "Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сәркатип,реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сәяси тормыш һәм тәрҗемә, фән һәм мәгариф
53-07-56 - мәдәният-сәнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - ВЛКСМның республика оешмасы, Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы.

Газета Татарстан республикасының Матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 4-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

*Редакциянең исәп-хисап счеты:*
*Р/с 700161998/700751 ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005*
*Индекс - 54121*
*Тираж - 200.000*

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе. Газета басылуга кул кую график буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 14 сәгатьтә кул куелды. Заказ 6043